**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге составына керүче Боерган авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

12 ноябрь, 2019 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 12 нояберендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:
«Боерган авыл җирлегенең Боерган авылы территориясендә 2020 елда балигъ булган, Боерган авыл җирлегенең Боерган авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 1000 (мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- Боерган авылында су башнясы урнаштыру һәм сууткәргеч челтәре сузу;
- -Боерган авылының Мирная урамы буенча юл салу”ны хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме

“ӘЙЕ” “ЮК”.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 338 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 174 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 174 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Боерган авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «Боерган авыл җирлегенең Боерган авылы территориясендә 2020 елда балигъ булган, Боерган авыл җирлегенең Боерган авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 1000 (мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз

карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- Боерган авылында су башнясы урнаштыру һәм суүткәргеч челтәре сузу;

-Боерган авылының Мирная урамы буенча юл салу” хәл итүгә юнәлдерүгә» мәсәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Боерган авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Боерган авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Боерган авыл җирлеге Башлыгы З.М.Камилҗанов